# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге составына керүче Биләр авылы торак пунктында

21 декабрь 2021 е. № 12

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге составына керүче Биләр авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда Биләр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган 1 төркем инвалидлардан, уку студентларыннан, гражданнардан тыш, гражданнарның үзара салымын 500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:
   - җирлек эчендәге юлларны тоту (юлларны кардан чистарту, юл читендәге үләннәрне чаптыру);
   - җирлек эчендәге юлларны ремонтлау һәм төзү (Комсомол ур., Украина ур., Совет ур., Киң ур.);
   - җирләү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (авария хәлендәге агачларны кисү һәм җыештыру, шартнамә буенча түләү);
   - техниканы - тракторны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча хезмәт өчен түләү);
   - торак пунктларда урамнарны яктырту;
   - суүткәргечне ремонтлау;
   - эре габаритлы чүп-чар җыю (айга бер тапкыр).

3. Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Биләр авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

4. Әлеге карарны Биләр авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Биләр авыл җирлеге советы бинасында Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Биләр авылы, Калинин урамы, 3 йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Г.Г.Хәбибуллин